СОВЕТ ОМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

“20” февраля 2023 г. — № 5-21

Омар авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы № 1-8 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273 ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 декабрендәге № 498-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Омар авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы № 1-8 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 7.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 11 пунктын өстәргә:

"11) аларга чит ил агенты статусын алу.";

1.2. Нигезләмәнең 7 бүлегендәге 7.1 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгын йә чит ил гражданлыгын (подданлыгын) туктату - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы.»;

1.3. Нигезләмәнең 12 бүлегендәге 12.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персональләштерелгән) исәп системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

1.4. Нигезләмәнең 12 бүлегендәге 12.19 пунктының 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

1.5. «Россия Федерациясе Пенсия фонды» Нигезләмәсенең 24 бүлегендәге 24.2 пунктының 4 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Мамадыш муниципаль районының Омар авыл җирлеге башлыгы вазифаларын башкаручы Р.Т.Галиуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары Р.Т.Галиуллин